СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 18 » апрель 2019 ел** **№ 247**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирлекләре бюджетына җирлектәге чыгым йөкләмәләрен башкаруны финанслар белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында»**

Профессиональ керемгә салым буенча салым потенциалын үстерүне стимуллаштыру максатында Татарстан Республикасы Арча муниципаль район Советы **карар чыгарды:**

1. Бирелгән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирлекләре бюджетына җирлектәге чыгым йөкләмәләрен башкаруны финанслар белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе Ф.Р.Исмәгыйлевка йөкләргә.

Арча муниципаль районы Башлыгы,
Район советы Рәисе

АРСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АРЧА РАЙОН СОВЕТЫ

И.Г.Нуриев

Кушымта
«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы
бюджетыннан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы
җирлекләре бюджетына җирлектәге чыгым йөкләмәләрен
башкаруны финанслар белән тәэмин итүгә башка бюджетара
трансфертлар бирү тәртибен раслау турында»
Татарстан Республикасы Арча муниципаль район Советы
карарына

«18» апрель, 2019 ел № 247

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан
Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирлекләре бюджетына
җирлектәге чыгым йөкләмәләрен башкаруны финанслар белән тәэмин итүгә
башка бюджетара трансфертлар бирү
Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирлекләре бюджетына башка төр бюджетара трансфертлар бирү (алга таба – башка бюджетара трансфертлар, муниципаль берәмлекләр) механизмын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасында профессиональ кремгә салым буенча салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатында Арча муниципаль районы җирлекләре бюджетларына җирлектәге чыгым йөкләмәләрен башкаруны финанслар белән тәэмин итүгә бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар җирлек бюджетларына билгеләнгән максатлар өчен чираттагы финанс елына һәм планлы чорга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджеты турында карары белән каралган бюджет ассигнованиеләре күләмендә чираттагы финанс елында квартал саен үткән кварталдан соң килүче айның 30 числосына кадәр бирелә.

4. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет чараларының төп оештыручысы булып «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – финанс-бюджет палатасы) тора.

5. Башка бюджетара трансфертларны бүлү Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

6. Күздә тотылган кварталга i- муниципаль берәмлеге башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$МТ_i^{кв} = НПД_i^{год} – НПД_i^{пт},$$

анда:

$МТ_i^{кв}$ – күздә тотылган квартал өчен i- муниципаль берәмлегенә бирелә торган башка бюджетара тарнсфертлар күләме, сум;

$НПД_i^{год}$ – Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында теркәлгән салым түләүчеләрдән i- муниципаль берәмлегеннән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетына кергән профессиональ керемгә салым суммасы, ел башыннан арта барып, сум;

$НПД_i^{пт}$ – Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында теркәлгән салым түләүчеләрдән i- муниципаль берәмлегеннән Татарстан Республикасы Арча

муниципаль районы бюджетына кергән профессиональ керемгә салым суммасы, башка бюджетара трансфертлар бирү максатында алдан исәпкә алынган, сум.

7. Муниципаль район составына кергән җирлек бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү шарты – җирлекнең башка бюджетара трансфертлар хисабына башкарыла торган чыгымнарын билгеләүче норматив хокукый акты булу.

8. Башка бюджетара тарснфертлар финанс-бюджет палатасы тарафыннан җирлек бюджетларына җирле бюджетлар үтәлешенең касса хезмәт күрәстүе өчен ачылган Татарстан Республикасы буенча Федераль Казначылык Идарәсе территориаль органнары исәп-хисап счетларына күчерелә.

9. Җирлекләрнең башкарма комитетлары (алга таба – җирлек башкарма комитетлары) финанс-бюджет палатасына башка бюджетара трансфертларны куллану турында финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгәнформада һәм тәртиптә башка бюджетара трансфертларны куллану турында хисап тапшыра.

10. Агымдагы финанс елының е1 гыйнварына кулланылмаган, әлеге Тәртип буенча алынган башка бюджетара трансфертлар агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Хисап финанс елында кулланылмаган башка бюджетара трансфертларда ихтыяҗ булу турында финанс-бюджет палатсы карары нигезендә агымдагы финанс елында әлеге башка бюджетара трансфертлар әлеге башка бюджетара трансфертларның калган күләменнән артмаган күләмдә бирелгән җирлек бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү максатларына туры килгән җирлек бюджеты чыгымнарын финас белән тәэмин итү максатларына кире кайтарыла ала.

Әлеге тәртиптә алынган башка бюджетара трансфертларның калган өлеше Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетына күчерелмәгән очракта әлеге акчалар Россия Федерациясе Финанс министрлыгы белән билгеләнгән гомуми таләпләр буенча финанс-бюджет палатасы билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетына кайтарыла.

11. Хисаптагы дөрес булмаган мәгълүмат һәм башка бюджетара трансфертлар бирү шартларының үтәлеше өчен Җирлек башкарма комитетлары һәм вазыйфаи затлар җавап бирә.

12. Башка бюджетара трансфертлар тапшыру шартларын бозган очракта әлеге акчалар Россия Федерациясе бюджет законнары белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетына күчерелә.

13. Әлеге Тәртип буенча бирелгән башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын Финас-бюджет палатасы тикшереп тора.